**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**23 март 2023 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 3**

**Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының “белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2022 елның 18 июлендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы прокуратурасының 16.01.2023 елның 02-08-0-23 номерлы «Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 18.07.2022 елның 28 июлендәге 2 номерлы» белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” карарына коррупция факторын бетерү турындагы протестына бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2022 елның 18 июлендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :

1) 2.7.3 пункты. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гаризаны һәм муниципаль хезмәт курсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчене кабул иткәндә дә, шулай ук җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) гаризаны теркәгән көннән алып 3 эш көненнән артмаган срокта ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне кулланып алганнан соң да кабул ителергә мөмкин.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Айбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Сафиуллин